КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 8 апрель г.Казань № 370

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 2 октябрь, 1207 нче, 2024 ел, 29 июнь, 480 нче, 2025 ел, 16 октябрь, 835 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

сигезенче абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «2014 – 2024 еллар чорына» сүзләрен «2014 – 2025 еллар чорына» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче – унҗиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«булган янгыннар саны 3 758 гә кадәр кимеде (2024 елда булган янгыннар саны 4 217 тәшкил иткән, 2023 елда - 4 968);

янгыннарда һәлак булучылар санының иң аз күрсәткече 2024 елда теркәлгән һәм 115 кеше тәшкил иткән  (2023 елда янгыннарда 143 кеше һәлак була, 2025 елда - 128 кеше);

янгыннарда зыян күрүчеләр саны 177 кешегә кадәр кимеде (2024 елда янгыннарда җәрәхәтләнүчеләр саны 202 кеше тәшкил итте, 2023 елда - 205 кеше);

су объектларындагы һәлакәтләр саны 95 кадәр кимеде (2024 елда суда һәлакәтләр саны 100 очрак тәшкил итте, 2023 елда - 106 очрак);

су объектларында һәлак булучылар санын арттыруга юл куелмаган (2025, 2024 һәм 2023 елларда суда һәлак булучылар саны 82 кеше тәшкил иткән);

су объектларында коткару очраклары саны суда һәлакәтләр саны кимүгә пропорциональ рәвештә кими (2025 елда суда 49 кеше коткарылган, 2024 елда - 38 кеше, 2023 елда - 68 кеше);»;

унтугызынчы һәм егерменче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системалары вазыйфаи затларын һәм белгечләрен  өзлексез әзерләү системасы оештырылды (2025 елда квалификация күтәрү узучылар саны 8 595 кеше тәшкил итте, 2024 елда - 8 612 кеше, 2023 елда - 14 255 кеше);

«112» бердәм номеры буенча кабул ителгән, эшкәртелгән һәм ашыгыч оператив хезмәтләргә җибәрелгән чакырулар саны  артты (2025 елда кабул ителгән һәм эшкәртелгән чакырулар саны – 22,7 миллион, 2024 елда 22 миллион чамасы, 2023 елда 21,5 миллион чамасы тәшкил итте);

II бүлектә:

алтынчы абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

III бүлекнең унөченче абзацында «хәрби низаглар вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлектә:

сигезенче абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин